ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422649, с. Бетьки,
ул. Мира, дом 2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘТКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422649, Бәтке авылы,
Тынычлык урамы, 2 нче йорт

Тел.: (84361) 26235, факс: (84361) 26235, e-mail:bet.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**23 май 2025 ел** **Бәтке ав.** **№49**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. файдаланудагы яисә хайван хуҗасы милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. авыл җирлеге территориясендә торак секторыннан һәм җәмәгать урыннарыннан читтә урнашкан буш, халык күпләп җыелмый торган урыннар, хуҗалары (ияләре) күзәтүе астында борынчыкларда (борынлыкларда) һәм йөгән тезгенендә.

2. Йорт хайваннарын йөртү гражданнарның, хайваннарның иминлеген тәэмин итү, физик затларның һәм юридик затларның мөлкәте саклану шарты белән башкарылырга тиеш.

2.1. Этне урамда йөртү озынлыгы этнең тотышын контрольдә тотарга мөмкинлек бирә торган бәйләвеч (тезген, йөгән) (этне тотып тора торган башка җайланма) кулланып башкарылырга тиеш (исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган, әлеге карарның 5 пункты нигезләмәләре кулланыла торган потенциаль куркыныч этләрне йөртүдән гайре).

3. Рөхсәт ителми:

3.1. йорт хайваннарын балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар территорияләрендә, массакүләм ял итү урыннарында, балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектлары янындагы территорияләрдә, хайваннар белән бергә йөрү өчен махсуслаштырылган объектлардан тыш, кибетләрдә ирекле йөртү; этләрне урамда йөргәндә караучысыз калдырырга;

3.2. этләрне алкоголь, наркотик яки токсик исерек хәлдә булган затлар, шулай ук яшь яки сәламәтлек торышы аркасында этләрнең хәрәкәтен контрольдә тота алмаган һәм урамда йөргәндә аларның агрессив тотышын искәртә алмаган затлар белән урамда йөртү.

3.3. пунктының гамәлдә булуы бәйләнчек этләргә кагылмый.

Йорт хайваны белән урамда йөргәндә барлык очракларда хуҗа үзе белән экскрементлар (калдыклар) җыю өчен предметлар йөртергә һәм, подъездлар, баскычлар, лифтлар, балалар мәйданчыклары, җәяүлеләр юллары, подваллар һәм торак йортларда һәм торак зоналарда гомуми файдаланудагы башка урыннарны да кертеп, кичекмәстән үзе белән булган йорт хайваннары артыннан экскрементлар җыярга тиеш.

4. Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган потенциаль куркыныч этләрне урамда йөртү, урамда йөрү урынына бәйсез рәвештә, борынчык һәм йөгәннән башка гына тыела, моңа потенциаль куркыныч эт милекчелек хокукында яисә башка законлы нигездә потенциаль куркыныч этнең хуҗасыныкы булган территориядә урнашкан булуы кирәк. Бу этнең барлыгы турында әлеге территориягә кергәндә кисәтү язуы эленергә тиеш.

5. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы, Ленин урамы, 4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов